**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 15 сентябрь № 681

г. Казань

2015 елда Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан бүтән бюджетара трансфертлар рәвешендә бирелә торган акчаны гражданнарны, шул исәптән социаль хезмәтләр җыелмасы рәвешендә дәүләт социаль ярдәмен алуга хокуклары булганнарны дарулар белән тәэмин итүне яхшырту максатында куллану тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 ел, 10 июнь, 1141-б боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Теркәлгән 2015 елда Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан бүтән бюджетара трансфертлар рәвешендә бирелә торган акчаны гражданнарны, шул исәптән социаль хезмәтләр җыелмасы рәвешендә дәүләт социаль ярдәмен алуга хокуклары булганнарны дарулар белән тәэмин итүне яхшырту максатында куллану тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 15 сентябрь, 681 нче
карары белән расланды

2015 елда Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан бүтән бюджетара трансфертлар рәвешендә бирелә торган акчаны гражданнарны, шул исәптән социаль хезмәтләр җыелмасы рәвешендә дәүләт социаль ярдәмен алуга хокуклары булганнарны дарулар белән тәэмин итүне яхшырту максатында куллану
**ТӘРТИБЕ**

1. Бу Тәртип 2015 елда Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан бүтән бюджетара трансфертлар рәвешендә бирелә торган акчаны (алга таба – акча) гражданнарны, шул исәптән социаль хезмәтләр җыелмасы рәвешендә дәүләт социаль ярдәмен алуга хокуклары булганнарны дарулар белән тәэмин итүне яхшырту максатында куллану механизмын билгели.

2. Акча Татарстан Республикасының гражданнарны, шул исәптән социаль хезмәтләр җыелмасы рәвешендә дәүләт социаль ярдәмен алуга хокуклары булганнарны дарулар белән тәэмин итү вәкаләтләрен тормышка ашыру белән бәйле бюджеттан чыгым йөкләмәләрен тәэмин итүгә юнәлдерелә.

3. Акчаны тотуны Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы гамәлгә ашыра.

4. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу тармагында контракт системасы турында Россия Федерациясе законнары нигезендә бу Тәртипнең 2 пункты нигезендә гражданнарга медицина ярдәме күрсәтү өчен дару препаратлары сатып алуны тәэмин итә.

5. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән бүтән бюджетара трансфертлар килү турында мәгълүмат алганнан соң аңарга билгеләнгән тәртиптә финанслауның чик күләмнәрен Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына җиткерүгә чыгым җәдвалы тапшыра.

6. Финанслауның җиткерелгән күләмнәре чикләрендә Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең акча килү турында хәбәрнамәләре һәм дару препаратларын китерүчеләрне билгеләү нәтиҗәләре нигезендә әлеге акчаны дәүләт контрактлары (шартнамәләре) төзелгән оешмаларга күчерүне гамәлгә ашыра.

7. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы квартал саен, хисап кварталыннан соң килүче айның 10 көненнән дә соңга калмыйча, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы раслаган форма буенча, финанс ягыннан тәэмин итү чыганаклары бүтән бюджетара

трансфертлар булган, бу Тәртипнең 2 пунктында каралган максатларга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары турында хисап тапшыра.

8. Акчаны максатка ярашлы файдаланмау бюджет законнары нигезендә җаваплылыкка китерә.

9. Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына тапшырылган белешмәләрнең дөреслеге өчен җаваплылык Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына йөкләнә.

---

F:\KARAR\2015\681.docx